

# Әти-әниләр өчен консультация
# “Хуш киләсен, матур яз!”





***Көннәр аяз, күктән алсу***
***Нур сибеп кояш көлә.***
***Җиргә тама көмеш тамчы –***
***Сагынып көткән яз килә.***



Яз да җитте. Кояш көннән-көн яктырак, ямьлерәк җылыта. Яз – балалар өчен иң файдалы һәм күңелле ел фасылы. Яз көннәрендә саф һавада йөрү-ул һәрвакыт кызыклы һәм файдалы дәрес. Язгы күренеш баланың сәламәтлеге һәм үсеше өчен файдалы. Бала белән урамда, паркта йөргәндә табигатьтә нинди үзгәрешләр баруы турында әңгәмә үткәрегез, сораулар бирергә тырышыгыз. Ничек бөреләр усә, беренче яфраклар, үләннәргә игътибар бирегез. Кошларны күзәтегез. Табигатьне күзәтү - бик бала өчен танып-белү дәресе. Ул балаларның табигать турында белемнәрен формалаштыра, табигатькә сакчыл караш тәрбияли.

Саф һавада уеннар - һәрвакыт күңелле һәм мавыктыргыч! Урамда, өйдә дә балагыз белән уйнагыз, - бу баланың әти-әни белән булган бәйләнешен ныгыта, шулай ук гаиләдә ышанычлы мөнәсәбәтләр булдырырга ярдәм итә.





# Күңелле язгы уеннар!

## «Тиз йөзүче кораблар»

Урамда елгалар ага яки күлләвекләр булса, анда кораб җибәрергә мөмкин. Әзер корабликны үзегез белән алып чыгарырга онытмагыз.



## « Мин фотограф»



Баланы матур күренешләрне (бөреләрне, бөреләрдән яшел яфрак чыкканын, төрле кошлар һәм бөҗәкләрне) фотога төшерергә өйрәтергә була.

## “Кем күбрәк?”

Урамда асфальт катламында кар эресә, балалар белән төрле рәсемнәр ясарга була.

## “Мин рәссам”

Мәсәлән, Кем күбрәк кош яки кем күбрәк күбәләк,агач саный. Күңелле һәм файдалы итеп урамда вакыт үткәрегез!



